ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур., 37в нчы йорт.
Тел.: 3-44-63
email: usin.akt@tatar.ru

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423739, д.Качкиново,
ул.Центральная, д.37в.
Тел.: 3-44-63
email: usin.akt@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

01.04.2020г. №9

**« Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетының 15.01. 2019 ел № 1 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1996 елның 31 маендагы "Оборона турында", 1998 елның 28 мартындагы "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында», 1997 елның 26 февралендәге "Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында", Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы "Хәрби исәпкә алу турында Нигезләмә" һәм 26.02.98 ел., 258 номерлы "Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запасында торучы Россия Федерациясе гражданнарын, федераль башкарма хакимият органнарын, запасы булган һәм дәүләт хакимияте органнарында, авыл җирлеге органнарында һәм оешмаларда эшләүче Россия Федерациясе гражданнарын броньлау буенча төп нигезләмәләр", федераль законнарны үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. « Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 15.01.2019 №1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең III бүлегенең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 3.2. Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядә яшәүче яки торучы (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлмәгән гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Усы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Усы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе З.З.Ахмаев